ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«06» июль 2021 ел                                                  № 101

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыруны оештыру турында» 2020 елның 30 декабрендәге 1265 номерлы карарын үтәү йөзеннән карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру комиссиясен төзергә.

2. Кушымта итеп бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын луны әзерләү һәм уздыру комиссиясе турында нигезләмәне;

- Арча муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру комиссиясе составын.

Килешү буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсен федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм җирле үзидарә органнары белән берлектә Арча муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыруга бәйле мәсьәләләр буенча (алга таба - авыл хуҗалыгы микросанын алу) вәкаләтле итеп билгеләргә.

4. Тәкъдим итәргә:

4.1 - Алабуга шәһәрендәге дәүләт статистикасы бүлегенә (Арча шәһәрендә) Арча муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белән берлектә Арча муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләргә һәм уздырырга.

4.2 - Арча шәһәре һәм авыл җирлегенең башкарма комитетлары җитәкчеләренә:

- 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру мәсьәләләрен хәл итүне тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасы буенча дәүләт статистикасының Арча бүлегенә тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын авыл хуҗалыгы микросанын алу объектлары турында белешмәләр җыюга җәлеп итүдә, шулай ук авыл хуҗалыгы микросанын алу объектлары турында белешмәләр җыюны, исәпкә алу кәгазьләрен һәм авыл хуҗалыгы микросанын алу документларын саклауны гамәлгә ашыручы затларны укыту һәм эшләү өчен яраклы урыннар сайлауга ярдәм итәргә;

- тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче җирдән файдаланучылар турында белешмәләрне, аларга беркетелгән җирнең мәйданы һәм 2021 елның 1 гыйнварына шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу күрсәткечләре нигезендә терлекләрнең актуальләштерелгән баш саны күрсәтеп, Арча дәүләт статистикасы бүлегенә билгеләнгән срокларда тапшыруны тәэмин итәргә;

- 2021 елда административ-территориаль берәмлекләрне һәм муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп коруны, шулай ук географик объектларның исемнәрен үзгәртүне планлаштырмаска.

4.3. Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлегенә авыл хуҗалыгы микросанын алу объектлары турында белешмәләр җыючы затлар эше өчен билгеләнгән биналарны саклауны тәэмин итүдә, исәп алу кәгазьләрен һәм авыл хуҗалыгы микросанын алуның башка документларын саклауда ярдәм күрсәтергә;

5. “ТАТМЕДИА” АҖ нең “Арча-информ” филиалына Арча муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру барышын яктыртырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Муниципаль район башлыгы И.Г. Нуриев

Арча муниципаль районы башлыгының
06 июль 2021 ел, № 101
карары белән расланды

**Арча муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру комиссиясе турында Нигезләмә**

1. Арча муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру комиссиясе (алга таба - Комиссия) Арча муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру буенча җирле үзидарә органнары, Алабуга шәһәрендәге дәүләт статистикасы бүлеге (Арча шәһәрендә), район предприятиеләре һәм оешмалары эшчәнлеген координацияләү өчен төзелде.

2. Комиссия үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары:

- җирле үзидарә органнарының, Алабуга шәһәрендәге дәүләт статистикасы бүлегенең (Арча шәһәрендә) Арча муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру, аның нәтиҗәләрен эшкәртү һәм бастырып чыгару буенча килешенгән гамәлләрне тәэмин итү;
- Арча муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итү;
- авыл хуҗалыгы микросанын алу объектлары исемлекләрен төзүдә ярдәм күрсәтү;
- халык арасында мәгълүмат-аңлату эшен оештыру, авыл хуҗалыгы микросанын алу максатларын аңлату;
- районда яшәүче гражданнарны авыл хуҗалыгы микросанын алу объектлары турында белешмәләр җыюга җәлеп итүне тәэмин итү;
- Арча муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләүнең һәм уздыруның барышын тикшереп торуны гамәлгә ашыру.

4. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

- район территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү, уздыру барышы турында Арча муниципаль районы җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкилләрен, Алабуга шәһәрендәге дәүләт статистикасы бүлеген (Арча шәһәрендә), район предприятиеләре һәм оешмалары вәкилләрен тыңларга;

- Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан, Алабуга шәһәрендәге дәүләт статистикасы бүлегеннән (Арча шәһәрендә), район предприятиеләре һәм оешмаларыннан 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм аны уздыру мәсьәләләре буенча материаллар соратып алырга;
- Арча муниципаль районы җирлекләренең җирле үзидарә органнарына, Алабуга шәһәрендәге дәүләт статистикасы бүлегенә (Арча шәһәрендә), район предприятиеләренә һәм оешмаларына 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алу мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр җибәрергә;
- Арча муниципаль районы җирлекләренең башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләрен һәм вазифаи затларын, массакүләм мәгълүмат чараларын, галимнәрне, белгечләрне комиссия утырышларына чакырырга;
- Комиссиягә йөкләнгән бурычларны хәл итүгә бәйле проблемалар буенча аерым тәкъдимнәр эшләү өчен вакытлы эшче төркемнәр төзергә.

5. Комиссия составы Арча муниципаль районы башлыгы тарафыннан раслана.

6. Комиссия рәистән, ике урынбасардан, Комиссия әгъзаларыннан һәм секретарьдан тора.

Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, мәсьәләләрне карау тәртибен билгели, Комиссия эшенең планнарын раслый, Комиссия составын төгәлләштерү һәм яңарту турында тәкъдимнәр кертә, аның утырышларын алып бара, Комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

Комиссия рәисе булмаганда яисә аның кушуы буенча рәис вазифаларын комиссия рәисе урынбасарларының берсе башкара.

7. Комиссия утырышлары Комиссия рәисе раслаган эш планы нигезендә кирәк булган саен, ләкин яртыеллыкта кимендә бер тапкыр уздырыла. Комиссия утырышлары, әгәр аларда аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала.

8. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга Комиссия рәисе яисә аның утырышта рәислек итүче урынбасары имза сала.

Арча муниципаль районы башлыгының
06 июль 2021 ел, № 101
карары белән расланды

**Арча муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгы микросанын алуны әзерләү һәм уздыру комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Нуриев Илшат Габделфәртович | - Арча муниципаль районы башлыгы, комиссия рәисе; |
| Мөхәмәтова Алсу Фирдәүсовна | - Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Гатиятов Ренат Мансурович | - Арча муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Әхмәтгалиев Булат Данилович | - Алабуга шәһәрендәге дәүләт статистикасы бүлегенең (Арча шәһәрендә) баш белгеч-эксперты, комиссия секретаре (килешү буенча). |
| ***Комиссия әгъзалары:*** | |
| Баһавиев Айдар Рашатович | - РФ Эчке эшләр Министрлыгының Арча районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Сираҗиев Илһам Гаптелнурович | - Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе урынбасары (килешү буенча); |
| Галимова Светлана Петровна | - «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ җитәкчесе (килешү буенча); |
| Касыймов Рөстәм Фәритович | - Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Мөхәмәдияров Рамил Данилович | - Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ башлыгы (килешү буенча); |
| Насыйбуллин Исрафил Рәхмәтуллович | - “ТАТМЕДИА” АҖ нең “Арча -информ” филиалы җитәкчесе (килешү буенча); |
| Нургалиев Илназ Тәлгатович | - Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Арча һәм Әтнә районнары буенча муниципальара бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Фәйзрахманов Руслан Ринатович | - Арча район дәүләт ветеринария берләшмәсе башлыгы (килешү буенча). |